ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2021 г. Заинск № 17

**"2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе программасын раслау турында"**

Балаларның коллектив музыкаль иҗатын үстерү, музыкага сәләтле балаларны ачыклау, аларга ярдәм итү, үстерү, аларның үз мөмкинлекләрен тормышка ашыруда, һөнәри үзбилгеләнешенә шартлар тудыру максатында, Бала хокуклары конвенциясенә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законына, «Мәдәният турында» 1998 елның 03 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе программасын расларга (кушымта).
2. "2018-2020 елларга Зәй муниципаль районында "Зәй балалар музыка мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесен үстерү программасын раслау турында" 2018 елның 27 августындагы 1396 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Д.Б. Коронова
8(85558)70063

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 16 январь
17 номерлы карарына
кушымта.

# 2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе программасы

**Зәй муниципаль районы 2021 ел**

**ЭЧТӘЛЕК**

Кереш сүз………………………………………………………………………...3

1. 2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе программасы паспорты……………………………………………………………………………4

2. «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеге турында мәгълүмати-аналитик белешмә:
2.1. Учреждение турында гомуми белешмәләр................................................ 7
2.2. Матди-техник база..................... ……………………………………………7
2.3. Кадрлар белән тәэмин ителеш……………………………………………… 8
2.4. Белем бирү процессына характеристика ……………………………….. 9
2.5. Функциональ идарә итү ………………………………………………11

3. 2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе программасын гамәлгә ашыру стратегиясе:
3.1. Мәктәп белән идарә итү системасын үстерү............................................11
3.2. Белем бирү процессын мәгълүмати тәэмин итү.........................................13
3.3. Укытучының методологик культурасы ................................................... 14
3.4. Мәктәпнең матди базасы...…………………………………………………15
3.5. Программаны финанслар белән тәэмин итү ............................................15
3.6. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре .................... 16
3.7. Үсеш программасының нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары …………. 16

Йомгаклау..………………………………………………………………………18

## Кереш сүз

Россия мәгарифен модернизацияләүнең төп бурычларыннан берсе булып заманча белем бирү сыйфатын тәэмин итү тора. Белем бирүнең сыйфаты төшенчәсе бала шәхесенең үсеш процессын һәм формалашуын, аның сәләтен тормышка ашыруны, мөстәкыйль иҗади гамәлләргә, даими һәм иҗади эзләнүгә омтылышын камилләштерүне үз эченә ала.

Бу мәсьәләне хәл итүдә, балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен, мәнфәгатьләрен, социаль һәм һөнәри үзбилгеләнешен үстерүнең иң нәтиҗәле формасы буларак, өстәмә белем бирүгә мөһим роль бирелә.

Өстәмә белем бирү системасының төп билгеләнеше һәр баланың белем бирү өлкәсен һәм өстәмә программа юнәлешен ирекле сайлау өчен шартлар тудырудан гыйбарәт.

Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү системасы, илебез мәгарифенең гомуми системасының бер өлеше буларак, теге яки бу тарихи чорда җәмгыять үсешенең үзенчәлекләрен ачыклый. Сәнгать өлкәсендә мәгариф системасының иң мөһим күрсәткече булып балалар музыка мәктәпләрендә белем бирүнең сыйфаты тора. Россия мәдәниятенең иң югары казанышларына музыка сәнгате өлкәсендә өзлексез белем бирүнең уникаль системасы («мәктәп-училище-югары уку йорты») нәтиҗәсендә ирешелде, ә аның нигезен балалар музыка мәктәпләре тәшкил итә. Бу мәктәпләр музыкаль сәнгать өлкәсендә традицион белгечлекләр буенча һөнәри әзерлек үзәкләре генә булып калмыйча, мәдәни толерантлык үсешенә, халыкларның мәдәни традицияләре арасында күпер булып торуга, төрле илләр һәм халыклар сәнгатен һәрьяклап өйрәнү һәм иҗади төшенү аша балалар һәм яшүсмерләрдә дөньяга караш формалаштыруга шактый дәрәҗәдә ярдәм итә.

Балалар музыка мәктәбе үзенең бөтен эшчәнлеген интеллектуаль иҗади мохит булдыруга әзер, илнең йөзен үзгәртергә сәләтле һәм аның югары көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итәрдәй актив иҗади потенциалга ия кешеләр әзерләүгә юнәлдерергә тиеш.

Шулай итеп, өстәмә музыкаль белем бирүнең сыйфатын күтәрү ярдәмендә үсеп килүче буынның югары гомумкультура дәрәҗәсен формалаштыру федераль, региональ һәм муниципаль хакимият органнарының беренче чираттагы бурычы булып тора.

Яңа иҗтимагый чынбарлык, соңгы елларда мәгариф системасында яңа реформалар, яңа педагогик һәм мәгълүмати-коммуникатив технологияләр актив кертелү белән бәйле рәвештә «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә 2021-2023 елларга исәпләнгән, мәктәпнең өстенлекле эш юнәлешләрен билгели торган үсеш программасы эшләнде. Әлеге Программа мәктәпне үстерү концепциясен төзергә, педагогик коллектив алдында торган юнәлешләрне һәм бурычларны эшләргә, матди чыгымнарны фаразларга һәм финанслау чыганакларын табарга мөмкинлек бирә.

## 1. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе үсеш программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Конституциясе;<br>Бала хокуклары турында конвенция (БМО Генераль ассамблеясе тарафыннан 1989 елның 20 ноябрендә хупланган);<br>"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Закон;<br>"Мәдәният турында" 1998 елның 3 июлендәге 170 номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы |
| Программаның муниципаль заказчысы (координаторы) | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |
| Программаның максаты | Музыкаль белем бирү һәм эстетик тәрбия бирү өлкәсендә гражданнарның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең белем бирү ихтыяҗларын канәгатьләндерү.<br>«ЗБММ» ӨБМБУ өстәмә музыкаль белем бирүнең сыйфатын күтәрү ярдәмендә үсеп килүче буынның югары гомумкультура дәрәҗәсен формалаштыру |
| Программаның бурычлары | - балаларның иҗади сәләтләрен үстерү, балаларның иҗади һәм шәхси үсешен тәэмин итү, шул исәптән балаларның табигый сәләтләрен үстерү, балаларда музыкаль һөнәри белем алу, гомуми эстетик белем алу өчен дә кирәкле күнекмәләр комплексы булдыру;<br>- өстәмә белем бирү системасы эшчәнлегенең төп шартлары булган һөнәр сайлау алды программаларын гамәлгә ашыруда сыйфат һәм дәвамчанлыкны тәэмин итү;<br>- тиз үзгәрә торган дөньяда үз һөнәри сыйфатларына туры килә торган урынны таба |

| | |
|---|---|
| | белүче иҗади-мобиль шәхес тәрбияләү;<br>- иҗади чаралар үткәрү юлы белән укучыларның иҗади эшчәнлеген оештыру (конкурслар, фестивальләр, олимпиадалар, концертлар, иҗат кичәләре, театральләштерелгән тамашалар һ. б.);<br>- мәдәни-агарту эшчәнлеге оештыру, шул исәптән, башка мәгариф учреждениеләре һәм мәдәният учреждениеләре белән берлектә (филармонияләр, театрлар, музейлар һ.б. белән);<br>- сыйфатлы музыкаль белемгә ихтыяҗны үстерү аша социаль заказ формалаштыруга йогынты ясау;<br>- шәхеснең төрле яклап иҗади үсешен һәм үз-үзен табуын, ил халкының мәдәни дәрәҗәсен күтәрү өчен заманча белем бирү мохите тудыру.<br>- мәктәп үсешенең хәзерге этабы максатларын һәм бурычларын исәпкә алып, укытучыларның һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру;<br>- белем бирү базарында музыка мәктәбенең конкурентлыкка сәләтлелеген арттыру; |
| Программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | **1 этап (2021 ел)**<br>**Максат:**<br>- аналитик эш башкару;<br>- мәктәпне үстерүнең норматив-хокукый базасын эшләү;<br>- мәктәпне үстерү программасын раслау;<br>- мәктәпнең укыту планын методологик яктан камилләштерү.<br>**2 этап (2022 ел)**<br>**Максат:**<br>- мәктәпнең үсеше программасын тормышка ашыру нәтиҗәләренә, белем бирү программаларына төзәтмәләр кертү (һөнәр сайлау алды һәм гомумүсештәге);<br>- укытуның заманча белем бирү технологияләрен киң кулланышка кертү.<br><br>**3 этап (2023 ел)**<br>**Максат:**<br>- үсеш программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә йомгак ясау;<br>- мәктәп үсешенең яңа стратегик планын эшләү. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2021-2023 елларга финанслауның гомуми күләме 58804,51 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: муниципаль бюджеттан - 57874,51 сум, бюджеттан |

| | |
|---|---|
| | тыш чаралар - 930 мең сум.<br><br>**2021 ел**<br>муниципаль бюджеттан - 19277.14 мең сум, бюджеттан тыш чаралар - 310.00 мең сум,<br>Барлыгы - 19 587.14 мең сум.<br><br>**2022 ел**<br>муниципаль бюджеттан - 19291.41 мең сум, бюджеттан тыш чаралар - 310.00 мең сум,<br>Барлыгы - 19 601.41 мең сум.<br><br>**2023 ел**<br>муниципаль бюджеттан - 19305.96 мең сум, бюджеттан тыш чаралар - 310.00 мең сум,<br>барлыгы - 19 615.96 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | Программаны 2021-2023 еллар дәвамында тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- балалар һәм яшьләрнең өстәмә белем алуда хокукларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән мәктәп тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатында уңай үзгәрешләргә;<br>- мәктәпнең матди-техник базасын һәм программа-методик тәэмин ителешен яхшыртуга;<br>- мәктәп эшчәнлегенең яңа юнәлешләрен үстерүгә;<br>- үзләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәргән укытучылар өлешен арттыруга;<br>- төрле дәрәҗәдәге конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашканда югары нәтиҗәләргә ирешүгә;<br>- коллективның казанышларга, үсешкә, үз-үзен үстерүгә юнәлгәнлегенә;<br>- методик һәм концерт-агарту эшчәнлеген оештыруның яңа дәрәҗәсенә чыгуга, традицион рәвештә үзебезнең музыкаль белем бирүнең югары дәрәҗәсен музыка педагогикасының инновацион казанышлары белән яраштыруга. |

## 2. «Зәй балалар музыка мәктәбе» ӨБМБУ эшчәнлеге турында мәгълүмати-аналитик белешмә

### 2.1. Учреждение турында гомуми мәгълүмат

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе, кыскартылган исеме: «ЗБММ» ӨБМБУ.

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2016 елның 27 апрелендә бирелгән, теркәү номеры - 8272, гамәлдә булу вакыты чикләнмәгән.

«Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе – белем бирү һәм иҗат итү өчен киң мөмкинлекләр бирә торган балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе: инструменталь башкару, ялгыз һәм хор белән җырлау.

Мәктәп ачылып эшли башлаганнан (1961 ел) соң аны 1300дән артык кеше тәмамлаган, аларның күбесе үз һөнәрләре итеп музыканы сайлаган. Дистәләгән элекке укучылар балалар иҗат йортларында, мәдәният сарайларында, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында музыка укытучылары һәм музыка җитәкчеләре булып эшли.

Мәктәпнең төп бурычы - профессиональ музыкантлар әзерләү генә түгел, ә беренче чиратта, музыкаль иҗат тормышларында төп һәм мөһим кызыксынуга әверелгән музыка сөючеләрне тәрбияләү.

### 2.2 Матди-техник база

«Зәй балалар музыка мәктәбе» ӨБМБУ Зәй шәһәренең Ленин урамы, 9а йорты адресы буенча урнашкан, 1718,7 квадрат метр мәйдан били торган ике катлы бинада эшчәнлек алып бара.

Музыка мәктәбе бинасында 204 урынга исәпләнгән концерт залы, музыка инструментлары һәм аудио- һәм видеоязмалар, слайдлар күрсәтү өчен махсус аппаратура һәм гамәли дәресләр үткәрү һәм музыкаль-эстетик эшчәнлек алып бару өчен уку әсбаплары белән җиһазландырылган индивидуаль һәм төркем белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирә торган (музыкаль-теоретик, хор һәм оркестрлар) 25 кабинет бар. Уку класслары яхшы хәлдә, норматив күрсәткечләр нигезендә җиһазландырылган. Музыкаль инструментларны эш халәтендә тоту өчен системалы рәвештә ремонт эшләре башкарыла.

Концерт залы уку һәм концертлар мәйданчыгы булып тора. Ул яңа тавыш аппаратурасы белән җиһазландырылган. Анда мәктәп күләмендә генә түгел, муниципаль масштабта да концерт-агарту чаралары, укучылар өчен академик концертлар һәм имтиханнар, хор, оркестр, инструменталь ансамбльләрнең репетицияләре уза.

Мәктәптә фондлары торымнан торымга яңартыла торган китапханә һәм фонотека бар. Ел дәвамында китапханә һәм фонотека хезмәтләреннән укытучылар да, укучылар да файдалана ала.

Укытучылар бүлмәсендә һәм китапханәдә МФУ урнаштырылган, алар ярдәмендә укучылар һәм укытучылар ноталарның ксерокопияләрен ясый ала.

Мәктәптә музыка коралларын прокатка бирү системасы җайга салынган, гардероб, велосипедлар кую урыны, кулерларда эчә торган чиста су бар.

Компьютерлар белән җиһазланган эш урыннары – музыка теориясе кабинетлары, администрация, бухгалтерия һәм канцелярия бүлмәләре.

Заманча белем бирү стандартларына туры килү өчен мәктәпкә интернетка тоташтырылган компьютер системасы, тавыш яздыру студиясе, электромузыка уен кораллары кабинетлары, уку әсбапларының заманча комплектлары, аудио-, видеоязмалар, заманча видео һәм тавыш ясау аппаратурасы кирәк.

## 2.3. Кадрлар белән тәэмин ителеш

Мәктәптә укытучылар һәм концертмейстерлардан торган югары профессиональ иҗат коллективы эшли, аның эшчәнлеге - хәзерге этапта мәгариф сәясәтенең төп бурычын хәл итүгә юнәлтелгән укучыларга сыйфатлы өстәмә белем бирү.

### 2.3.1 Сыйфат составы буенча кадрлар

| Укытучыларның гомуми саны | Исеме,гыйльми дәрәҗәсе булган педагоглар | "Мәдәни яттә казанышлары өчен" билгесе булган педагоглар | Квалификация категорияләре | | | | Белем дәрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | югары | I | II | биләгән вазыйфага туры килү | югары белемле | махсус урта белемле | Читтән торып белем ала |
| 24 | Атказанган мәдәният хезмәткәре 3 12,5% | 9 37,5% | 20 83,4% | 2 8,3% | - | 2 8,3% | 15 62,5% | 9 37,5% | - |

### 2.3.2 Кадрларның яше

| Укытучыларның гомуми саны. | шулардан | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 25 яшькә кадәр | 25 - 35 яшьтәгеләр | 35 - 55 (60 ир-ат.) | Пенсия яшендәгеләр |
| 24 | 0 | 1 4% | 11 46% | 12 50% |

Уртача яшь: 52

Педагогик коллективның һөнәри осталыгы сыйфаты үсеше квалификация категорияләренең тотрыклы үсүе белән раслана, ә иң яхшы укытучылар һәм укучыларның иҗади казанышлары күптән бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәгә чыкты.

Мәктәп укытучыларының 65 проценты - шушы музыка мәктәбен тәмамлаучылар, мәктәп ачылган көннән эшләүче ветераннар да бар. Шулай итеп, педагогик һәм мәдәни-әхлакый тәрбия традицияләре мәктәптә буыннан буынга

күчеп яши, бу мәктәпнең гомуми атмосферасы өчен дә, укыту-тәрбия процессының нәтиҗәлелегенә ирешү өчен дә мөһим.

Мәктәпне якындагы 3 елга кадрлар белән тәэмин итү перспективаларын фаразлап, музыка мәктәбенә югары уку йортларыннан яшь белгечләрне җәлеп итү буенча актив эш алып барырга кирәк.

## 2.4. Белем бирү процессына характеристика

"Зәй балалар музыка мәктәбе" ӨБМБУ балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү өлкәсендә түбәндәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген башкара:

- өстәмә һөнәр сайлау алды гомуми белем бирү программалары;
- өстәмә гомуми үстерү гомуми белем бирү программалары.

Белем дәрәҗәсе: сәнгать өлкәсендә өстәмә башлангыч белем.

Укыту формасы: көндезге.

Уку вакыты: 5 ел, 7 ел, 8 ел.

Белем бирү программалары музыкаль сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри белем алды гомуми белем бирү программасына карата федераль дәүләт таләпләре, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының сәнгать өлкәсендә гомуми үсеш алган программаларны гамәлгә ашырганда белем бирү һәм методик эшчәнлекне оештыру буенча рекомендацияләре нигезендә мәктәп тарафыннан мөстәкыйль эшләнә.

Белем бирү программалары мәктәптә белем бирүнең эчтәлеген билгели һәм балаларның яшь үзенчәлеген исәпкә ала. Программалар белем бирүгә дифференциаль якын килеп төзелә, бу сәләтләре төрлечә булган укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүне күздә тотып эшләнә.

Мәктәптә белем бирү процессын оештыру уку планнары, еллык календарь уку графигы һәм мәктәп тарафыннан мөстәкыйль эшләнә һәм раслана торган дәресләр расписаниесе белән регламентлана.

Укучыларның үзенчәлекләрен, укуга индивидуаль якын килүне исәпкә алып, уку процессын оештыру өчен уңайлы шартлар тудыру эшчәнлекнең мәҗбүри шарты булып тора. Бу һәр баланың үсеш перспективаларын төгәлрәк билгеләргә һәм, шуның белән бергә, күп кенә балаларга сәнгать белеме процессына кушылырга, иҗади потенциалын ачарга мөмкинлек бирә.

Дәресләрне оештыру расписание (индивидуаль һәм төркем) нигезендә гамәлгә ашырыла, анда сыйныфлар һәм укыту төркемнәре, дәресләрнең вакыты һәм озынлыгы, аудитория һәм дәресләрне алып баручы укытучыларның фамилиясе күрсәтелә. Укучылар төркемнәренең сан составы уку планнары нигезендә билгеләнә.

Музыка мәктәбе укучылары контингенты - 271 кеше.

Бүгенге көндә мәктәптә балалар 15 белгечлек буенча белем ала: хор белән җырлау, фортепиано, скрипка, виолончель, думбра, балалайка, флейта, саксофон, торба, баян, аккордеон, гитара, тромбон, кларнет, валторна.

Уку процессында белгечлекләр буенча түбәндәге предметлар бар:

- музыкаль инструмент;

- сольфеджио;
- музыка тыңлау (беренче клас укучылары өчен бишьеллык программа буенча һәм беренче-өченче класс укучылары өчен җиде һәм сигезьеллык программа буенча);
-музыка әдәбияты (икенче-бишенче класс укучылары өчен - бишьеллык программа буенча һәм дүртенче-җиденче (сигезенче) класс укучылары өчен - җиде еллык (сигезьеллык) программа буенча);
- хор;
- инструменталь ансамбль;
- аккомпанемент;
- дирижерлык нигезләре;
- вокаль ансамбль;
- гомуми фортепиано;
- танышу;
- импровизация;
- оркестр.

Музыка мәктәбендә егермедән артык төрле коллектив бар. Шулар арасында - халык уен кораллары оркестры (җитәкчесе Коклина Е.А.), "Фестиваль" эстрада-симфоник оркестры, «Дикси» ансамбле (җитәкчесе Шамов А.А.), тынлы оркестр (җитәкчесе Бурмистрова Н.Н.), «Чылтыр чишмә" инструменталь татар фольклор ансамбле (җитәкчесе Красильникова О. Г.), «Cantabile» виолончелистлар ансамбле (җитәкчесе Кадыйрова Л.П.), вокаль ансамбльләр (җитәкчесе Долгова З.Р.), «Ювента» ансамбле (җитәкчесе Селиверстова З.Х.,), «Лель» халык җырлары ансамбле (җитәкчеләре Рыжова И.С., Гыйлаева Л.Р.), «Акварель» скрипкачылар ансамбле (җитәкчесе Блинова Р.З.), думбрачылар ансамбле (җитәкчесе Коклина Е.А.), кечкенәләр хоры (җитәкчесе Гыйлаева Л.Р.), уртанчылар хоры, зурлар хоры (җитәкчесе Долгова З.Р.) һәм башкалар бар.

Укытуга мондый актив иҗади якын килү нәтиҗәсе буларак, «Зәй музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе укучыларының да, укытучыларның да төбәк дәрәҗәсеннән алып, халыкара фестивальләрдә даими җиңүләр яулавы һәм төрле дәрәҗәдәге конкурс һәм фестивальләр лауреатлары булуы гаҗәп түгел.

## 2.5. Функциональ идарә

Мәктәп белән турыдан-туры директор идарә итә.

Укыту-тәрбия эше буенча җитәкче урынбасары учреждениенең белем бирү эшчәнлеген агымдагы һәм перспективага планлаштыруны оештыра.

Административ-хуҗалык эше (АХЭ) буенча җитәкче урынбасары учреждениенең хуҗалык эшчәнлегенә җитәкчелек итә.

Ата-аналар комитеты белем бирү процессын оештыру өчен уңай шартлар тудыруга булыша, балалар иҗаты конкурслары һәм фестивальләре үткәрүдә, укучыларның күчмә гастрольләрдә һәм конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашуына ярдәм итә.

Мәктәп белән идарә итү процессында мәктәпнең бүлекләр җитәкчеләре, шулай ук директор, укыту эшләре буенча җитәкче урынбасары һәм профсоюз оешмасы рәисе кергән орган – мәктәпнең педагогик советы катнаша. Аның максаты булып белем бирү процессын камилләштерү тора (шул исәптән-белем бирү программаларын, укыту рәвешләрен һәм методларын камилләштерү).

Педагогик совет укыту процессының төп мәсьәләләрен карый. Педагогик совет утырышларында киләсе елга эш планнары проектлары тикшерелә, укучыларның арадаш һәм йомгаклау аттестацияләренә нәтиҗә ясала, уку процессы проблемалары тикшерелә, устав документлары, локаль актлар, мәктәп эшчәнлегенең төрле яклары турында нигезләмәләр, календарь планнары раслана.

## 3. «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесен үстерү программасын тормышка ашыру стратегиясе

### 3.1. Мәктәп белән идарә итү системасын үстерү

МАКСАТЛАР:

1. Мәктәп эшчәнлеген җәелдерү.
2. Белем бирү процессы субъектларының үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен оештыру-педагогик шартлар тудыру.

БУРЫЧЛАР:

1. Педагогик менеджмент принциплары нигезендә мәктәп белән идарә итү функцияләрен яңарту.
2. Югары белем бирүне тәэмин итү, укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру.
3.Мәгариф процессы субъектларының бердәм килештерелгән педагогик максатларга ирешүендә көчләрне координацияләү.
4. Педагогик һәм идарәче кадрларның һөнәри компетентлык дәрәҗәсен күтәрү
5. Мәктәпне үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү.

ГАМӘЛГӘ АШЫРУ:

| № | Чаралар | Срогы | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәптә аналитик эшчәнлекне камилләштерү, программаны тормышка ашыру планы буенча төп проблемаларны ачыклау | 2021-2023 еллар | директор, мәктәпнең методик советы |
| 2. | Мәктәпнең идарә звеносын һәм кадрлар резервын киләчәктә һөнәри әзерләүне тәэмин итү | 2021-2023 еллар | директор |
| 3. | Һөнәр алды һәм гомуми үсеш программаларын кертү планында мәктәп бүлекләре мөдирләренең эшчәнлеген җәелдерү | 2021-2023 еллар | директор, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, методист |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Инновацион эшчәнлек белән идарә итү нигезе буларак мәктәп үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү | ел саен | директор, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, мәктәпнең пед. советы |
| 5. | Мәктәп белән идарә итү системасының мәгълүматлар базасын камилләштерү. | ел саен | директор, кадрлар эшләре буенча белгеч |
| 6. | Мәктәпнең методик советы эшчәнлегенә анализ | ел саен | директор, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, методист, бүлек мөдирләре |
| 7. | Хезмәткәрләрне финанс ягыннан кызыксындыру системасын камилләштерү | ел саен | директор, мәктәпнең пед. советы |
| 8. | Ата-аналар һәм укучыларның фикерләрен даими өйрәнү, социаль заказны билгеләү. | ел саен | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары |

КӨТЕЛӘ ТОРГАН НӘТИҖӘЛӘР:

- музыка мәктәбе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тагын да арттыру;
- мәктәп белән идарә итүдә белем бирү процессы субъектларының катнашу мөмкинлекләрен киңәйтү;
- педагогик кадрларның һөнәри компетентлыгын арттыру;
- укытучыларның социаль яклanганлыгын арттыру

### 3.2. Белем бирү процессын мәгълүмати тәэмин итү

МАКСАТЛАР:

- мәктәп эшчәнлеге һәм үсеш процессларын мәгълүмати тәэмин итү механизмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү
- укытучыларның һәм укучыларның мәгълүмати культурасын күтәрү.

БУРЫЧЛАР:

- мәгълүмат алу, эшкәртү һәм куллану өлкәсендә укытучыларны һәм укучыларны максатчан әзерләүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;
- идарә итү бәйле мәсьәләләрнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен мәгълүмат системаларын куллану;
- мәктәпнең укыту-тәрбия процессына заманча мәгълүмати технологияләрне киң кертү;

- мәктәп, аның казанышлары һәм өстенлекләре турында халыкка мәгълүмат бирү системасын камилләштерү.

ГАМӘЛГӘ АШЫРУ:

| № | Чаралар | Срогы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Укыту процессын мәгълүмати тәэмин итү концепциясен эшләү | 2021-2023 еллар | директор, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, бүлек мөдирләре |
| 2. | Компьютер базасында мәктәп эшен алып бару. | даими | директор, кадрлар эше буенча белгеч |
| 3. | Мәктәп эшчәнлеге турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерү (шул исәптән мәктәп сайты) | даими | кадрлар эше буенча белгеч, методист. |

КӨТЕЛӘ ТОРГАН НӘТИҖӘЛӘР:

- белем бирү процессын мәгълүмати тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын булдыру;
- мәгълүмати җәмгыять шартларында укучыларны һәм укытучыларны тормышка һәм эшчәнлеккә әзерләү;
- укытучыларның һөнәри эшчәнлеген фәнни-методик тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү;
- Татарстан, Россия Федерациясе шәһәрләре һәм башка дәүләтләрнең балалар һәм яшүсмерләр өчен иң яхшы музыка мәктәпләре, колледжлары һәм башка уку йортлары укучыларының югары һөнәри дәрәҗәсе һәм башкару эшчәнлеге белән танышу;
- белем алуга гражданнарның хокукларын тулысынча тормышка ашыру максаты белән белем бирү процессында катнашучыларның мәгълүматлылыгын киңәйтү.

### 3.3. Укытучының методологик культурасы

МАКСАТ:

Мәктәп укытучыларының һөнәри осталыгын арттыру өчен шартлар тудыру.

БУРЫЧЛАР:

1. Педагогика, фәннәрне укыту теориясе һәм методикасы, заманча педагогик технологияләр өлкәсендә укытучыларның теоретик әзерлеге дәрәҗәсен күтәрү;
2. Һөнәри компетентлыкны арттыру максатларында укытучыларны яңадан укытуны һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыру;
3. Укытучыларның иҗади потенциалын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган конкурслар, презентацияләр, проектлар һ. б.ның системасын эшләү.

ГАМӘЛГӘ АШЫРУ:

| № | Чаралар | Срогы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Укытучыларның квалификациясен күтәрү | Ел саен | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары |
| 2. | Мәгарифне модернизацияләүнең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга укытучыларны әзерләү | 2021-2023 еллар | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары |
| 3. | Методик эшләр буенча республика конкурсында катнашу | ел сан | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, бүлек мөдирләре |
| 4. | Педагогларның инновацион эшчәнлеген стимуллаштыру системасын камилләштерү | 2021-2023 еллар | директор |
| 5. | Төрле дәрәҗәдәге педагогик казанышлар конкурсларында, шул исәптән грант конкурсларында катнашу | 2021-2023 еллар | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, бүлек мөдирләре |
| 6. | Укытучыларның казанышларын мәгълүмат чаралары ярдәмендә социализацияләү (мәктәп сайтында педагогларның шәхси битләрен булдыру) | 2021-2023 еллар | укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, методист, бүлек мөдирләре |

КӨТЕЛӘ ТОРГАН НӘТИҖӘЛӘР:
- укытучыларның гомуммәдәни һәм һөнәри компетентлыгы үсеше;
- педагогик эшчәнлек барышында һөнәри осталыкны арттыруның адаптив системасын булдыру;
- укытуның сыйфаты күтәрелү;
- мәктәп укытучыларының социаль-һөнәри статусы үсеше.

### 3.4. Мәктәпнең матди базасы

МАКСАТЛАР:
1. Мәктәпне җитешмәгән җиһазлар һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итү.
БУРЫЧЛАР:
1. Китапханә фондын даими яңарту.
2. Уку базасын һәм уку кабинетларында күрсәтмә әсбапларны яңарту.

ГАМӘЛГӘ АШЫРУ:

| № | Чаралар | Срогы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Инвентаризациялəгəндə матди кыйммəтлəрне исəпкə алу һəм анализлау | Елга бер мəртəбə | АХЭ буенча директор урынбасары |
| 2. | Уку базасын камиллəштерү өчен кабинетларны кирəкле материаллар һəм күрсəтмə əсбаплар белəн тəэмин итү | Ел саен | директор, АХЭ буенча директор урынбасары |
| 3. | Теория классларын компьютерлаштыру | 2021 ел | директор, АХЭ буенча директор урынбасары |
| 4. | Китапханəне комплектлау | даими | АХЭ буенча директор урынбасары, китапханəче |
| 5. | Мəктəп кабинетларында күрсəтмə əсбаплар фондын яңарту | Ел саен | АХЭ буенча директор урынбасары |

КӨТЕЛӘ ТОРГАН НӘТИҖӘЛӘР:
- повышение качества учебно-воспитательного процесса;
- создание оптимальных условий для работы преподавателей;
-приведение материальной базы учебного процесса в соответствие с современными санитарно-гигиеническими требованиями;
-обеспечение соблюдения правил техники безопасности при проведении учебных занятий и концертных мероприятий.

### 3.5. Программаны финанслар белəн тəэмин итү

Программаны финанс белəн тəэмин итү муниципаль бюджет акчалары һəм законнар белəн тыелмаган башка чыганаклар хисабына гамəлгə ашырыла.

Программаны гамəлгə ашыруның бөтен чорына муниципаль бюджет һəм бюджеттан тыш акчалар хисабына чараларны финанслауның фаразланган күлəме 58 804,51 мең сум тəшкил итə, түбəндə елларга бүлеп күрсəтелə:

(мең сумнарда)

| Финанслау чыганаклары | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | Барысы |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль бюджет | 19 277.14 | 19 291.41 | 19 305.96 | 57 874.51 |
| Бюджеттан тыш средстволар | 310.00 | 310.00 | 310.00 | 930.00 |
| Барысы: | 19 587.14 | 19 601.41 | 19 615.96 | 58 804.51 |

### 3.6. Программаны тормышка ашыруның көтелгəн нəтиҗəлəре

Әлеге программаны уңышлы тормышка ашырганда көтелә:
1. Укучыларны укыту һәм тәрбияләүнең сыйфаты күтәрелү;
2. Белем бирү процессының барлык субъектларының гомуми максатчан кыйммәтләр кыры белән характерлана торган мәктәпнең бердәм белем бирү мохите формалашу.
3. Социологик сорашып белешүләр нәтиҗәләре белән расланган мәктәпнең белем бирү процессының барлык субъектларын җәлеп итә торган имиджы булдырыла.
4. Белем бирү процессының барлык субъектларының белем бирү һәм иҗат казанышлары үсү (конкурсларда, фестивальләрдә, проектларда катнашу һ.б.).
5. Сәләтле балаларны ачыклау, аларны алга таба һөнәри белем алуга, мәктәпне тамамлаучыларның урта һәм югары һөнәри уку йортларына укырга керүен арттыруга юнәлеш тоту;
6. Укучыларның уку-укыту, фәнни-тикшеренү һәм дәрестән тыш эшчәнлек процессында үз-үзләрен үстерү күнекмәләрен формалаштыруда уңышка ирешүгә мотивациясен арттыру;
7. Үткәрелә торган дәресләрнең һәм аларның гамәли юнәлешләренең нәтиҗәлелеген арттыру;
8. Иҗади сәләтле балаларның төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыру.
9. Белем бирү учреждениесенең статусын күтәрү.
10. Ата-аналарны белем бирү процессына актив тарту.
11. Белем бирү процессында катнашучыларның белем бирү дәрәҗәсе һәм сыйфаты белән канәгать булуы.

## 3.7. «ЗБММ» ӨБМБУ үсеш программасы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| **Чаралар** | **Башкару чылар** | **Төп чараларны башкару сроклары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге** | **Индикаторларның күрсәткече** | | | **Чыганакны күрсәтеп, финанслау (мең сумнарда)** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| 1. Мәктәп укытучыларының һөнәри осталыгын арттыру өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | |
| Укытучыларны аттестацияләү | Мәктәп укытучылары | Һәр биш ел саен | Квалификация категориясен алган яисә раслаган кеше саны | 5 кеше | 6 кеше | 3 кеше | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Квалификация күтәрү курслары узу | Мәктәп укытучылары | Өч ел саен | Квалификацияне күтәргән кеше саны | 14 кеше | 8 кеше | 5 кеше | 52 мең (бюджет) 4 (бюджет тан тыш) | 28 мең (бюджет) 4 (бюджет тан тыш) | 16 мең (бюджет) 4 (бюджет тан тыш) |
| Участие в конкурсах педагогических достижений разных уровней | Мәктәп укытучылары | Ел саен | Һөнәри һәм методик осталык конкурслары саны | 7 конкурс | 8 конкурс | 9 конкурс | - | - | - |
| 2. Белем бирү процессының барлык субъектларының белем һәм иҗат казанышларының үсеше | | | | | | | | | |
| Укучылар контингенты тотрыклылыгы | Мәктәпнең укытучылары һәм укучылары | Даими | Укучылар саны | 271 кеше | 271 кеше | 271 кеше | - | - | - |
| Белем бирүнең сыйфатын саклау | Укытучылар һәм укучылар | Даими | Белем бирү программаларын уңышлы үзләштергән укучыларның процентлары | 100% | 100% | 100% | - | - | - |
| Төрле дәрәҗәдәге башкару осталыгы конкурсларында катнашу | Укытучылар һәм укучылар | Ел саен | Башкару осталыгы конкурслары саны | 40 | 41 | 42 | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иҗади чаралар (концертлар, фестивальләр, конкурслар) үткәрү, шул исәптән ата-аналар белән берлектә | Укытучылар һәм укучылар | Ел саен | Чаралар саны | 45 | 46 | 47 | 50 (бюджет) | 50 (бюджет) | 50 (бюджет) |

## Йомгаклау

Балалар музыка мәктәпләренең бурычы - гармонияле үсештәге, иҗади актив шәхес тәрбияләү. Алар укучыларга музыкаль белем биреп кенә калмый, шул ук вакытта урта махсус уку йортлары өчен кадрлар да әзерлиләр. Үзара бәйләнештәге бу ике мәсьәләне хәл итү балалар музыка мәктәбе педагогик коллективы эшчәнлегенең төп бурычы булып тора.

Педагогик коллективның игътибары заманча музыка педагогикасының төп бурычына - укучыларны һәрьяклап комплекслы тәрбияләүне камилләштерүгә юнәлтелергә тиеш. Бу процесста белем бирүнең яңа ысулларын киң куллану нигезендә укытуны камилләштерү мөһим роль уйнарга тиеш. Ә бу исә балаларда музыкага кызыксыну уятырга һәм аларның иҗади көчләрен популярлаштыруга ярдәм итә.

Бүгенге шартларда музыка мәктәбе прогрессив методикаларны эзләү һәм тиешле педагогик тәҗрибәләр үткәрүнең инициаторы булырга тиеш. Эзләнүләр белән җитәкчелек итү һәм аны оештыра белү мәктәп администрациясе һәм әйдәп баручы педагогларның бурычы булып тора.

Мәктәпнең миссиясе - үсеп килүче буынны музыка сәнгате өлкәсендә сәнгати-эстетик иҗат чаралары ярдәмендә рухи-әхлакый яктан үстерү, һәр укучының, аның психофизиологик үзенчәлекләренә һәм уку мөмкинлекләренә, сәләте дәрәҗәсенә карамастан, үз мөмкинлекләрен тормышка ашырырга ярдәм итәрдәй белем бирү мохите булдыру.

Укучыларның төрле яклап музыкаль үсешенә укыту-тәрбия эшенең көндәлек дәресләр процессында гына түгел, ә укучының өлгерешен бәяләгәндә тиешле игътибар бирелсә генә ирешелергә мөмкин. Шуңа күрә хәзерге этапта укыту процессын камилләштерүнең мөһим юнәлеше булып яшь музыкантны төрле яклап комплекслы тәрбияләүнең ролен көчәйтү, бала шәхесенең музыкаль үсешеннән чыгып, эш нәтиҗәләрен мөмкин кадәр комплекслы бәяләү тора.

Нәкъ менә сәнгати-эстетик тәрбия мәгариф системасының барлык баскычларына да бик кирәк, чөнки ул шәхесне рухи яктан үстерергә, аның эмоциональ өлкәсенә йогынты ясарга сәләтле. Иҗади сәләтләрне үстерүдә,

шәхеснең үзенчәлекләрен һәм сыйфатларын, эчке дөньясын формалаштыруда нәкъ менә эмоциональ башлангычка төп әһәмият бирелә.

Эстетик тәрбия процессын гамәлгә ашырып, музыка мәктәбе, бер яктан, кеше шәхесен үстерү өчен кирәк булган мәдәни мохит формалаштыруга ярдәм итә, икенче яктан, сәләтле укучыларны ачыклый һәм аларны, һөнәри белем бирүнең беренче баскычы буларак, һөнәри белем бирүне дәвам итүгә әзерли.

Укыту һәм үстерү бердәм процессының тәрбияви өлешен тәшкил итүгә юнәлдерелгән балалар музыка мәктәпләрендә заманча өстәмә белем бирү кешенең үз-үзе белән гармониясен, башка кешеләр, җәмгыять, табигать, кеше эшчәнлеге белән гармонияне билгеләү аша тәэмин итәргә ярдәм итәчәк.